КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 май г.Казань № 446

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турындагы нигезләмәдә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыру сменасында катнашучылар:

6,5 яшьтән 18 яшькә кадәрге гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылар;

муниципаль һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалары;

коммерция һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалары;

кадет мәктәпләрендә һәм гомуми белем бирү хәрби училищеларында 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге тәрбияләнүчеләр;

өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы, аларны үзләштерүче 7 яшьтән 30 яшькә (30 яшьне кертеп) кадәрге иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар, спорт әзерлеген узучы балалар, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен тормышка ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан, якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалар

һәм яшьләр;

хроник авыруларына ия, торгызу дәвалавына мохтаҗ булган 4 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге (шул исәптән ата-аналарның берсе (яки законлы вәкилләр) тарафыннан даими булышлык күрсәтелеп торган) балалар;

тормышта авыр хәлдә калган балалар, шул исәптән:

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге тәрбияләнүчеләр, опекун һәм тәрбиягә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балалар;

озатып йөрелә һәм озатып йөрелми торган 4 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге инвалид балалар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикле балалар;

социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүчеләр;

социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдән 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге балалар;

девиант тәртипле укучылар өчен мәгариф оешмаларында булучы (профилактик исәптә торучы) 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге балалар;

барлыкка килгән шартлар аркасында тормыш эшчәнлеге объектив рәвештә бозылган һәм әлеге шартларны мөстәкыйль яки гаилә ярдәме белән җиңә алмаган 7 яшьтән 18 яшькә (18 яшьне кертеп) кадәрге балалар;

җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган, бала өчен ай саен пособие алган гаиләләрдән (аз керемле һәм аз тәэмин ителүче гаиләләр) 7 яшьтән 15 яшькә кадәрге (15 яшьне кертеп) балалар;

югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларының 18 яшьтән 30 яшькә (30 яшьне кертеп) кадәрге студентлары.»;

3.3 пунктта:

дүртенче абзацта «профилактик исәптә торучы балалар» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче – җиденче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«профилактик исәптә торучы балалар өчен палатка тибындагы лагерьлардагы сменаларны;

тормышта авыр хәлдә калган 7 яшьтән 15 яшькә (15 яшьне кертеп) кадәрге балалар өчен шәһәр яны ял һәм савыктыру лагерендагы сменаларны.»;

4.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы һәм аларны үзләштерүче, халыкара һәм төбәкара дәрәҗәдәге предметлар олимпиадаларында һәм спорт чараларында уңышларга ирешүче иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар өчен шәһәр яны ял лагерьларында, шул исәптән Кара диңгез яры буйларында; хәрби-патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән сменаларның иҗади сәләтле һәм социаль актив балалары һәм анда катнашучылар өчен палатка тибындагы лагерьларда; гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен хезмәт һәм ял лагерьларында; тормышта авыр хәлдә калган балалар өчен ял оешмаларында профильле сменаларда тиешле финанс елына балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга норматив чыгымнарның 100 процентын.»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Лагерьларда балалар һәм яшьләр ялы өчен ата-ана түләве күләме ял оешмалары тарафыннан билгеләнә. Балалар һәм яшьләр ялы өчен ата-ана түләвенең минималь күләме тиешле финанс елына расланган балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга норматив чыгымнарның 15 проценты күләмендә билгеләнә. Әгәр норматив чыгымнарда күрсәтелә торган хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез булган чыгымнар чагылдырмаса, юлламаның факттагы кыйммәте белән Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акча өлеше арасындагы аерма ата-аналар (яки законлы вәкилләр), оешмалар тарафыннан, әмма дәүләт һәм муниципаль ял оешмалары өчен юлламаның факттагы кыйммәтеннән 50 процент артмаган күләмдә түләнә.»;

5.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Татарстан Республикасы территориясендәге лагерьларда балалар һәм яшьләр ялы һәм аларны савыктыру өчен ата-ана түләве түбәндәгеләрдән алынмый:

өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы һәм аларны үзләштерүче, халыкара һәм төбәкара дәрәҗәдәге предметлар олимпиадаларында һәм спорт чараларында уңышларга ирешүче иҗади сәләтле һәм социаль актив балалардан;

палатка тибындагы лагерьларда хәрби-патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән сменаларның иҗади сәләтле һәм социаль актив балаларыннан һәм аларда катнашучылардан;

хезмәт һәм ял лагерьларында гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылардан;

тормышта авыр хәлдә калган балалардан;

хроник авырулары булган, шул исәптән ата-ананың берсе (яки законлы вәкилләр) озатып йөри торган балалардан.»;

8.1 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

11.2 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

11.4 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга, «республика» сүзен төшереп калдырырга;

11.5 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы боерыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

11.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

13 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Шәһәр яны ял лагерьларындагы, шул исәптән Кара диңгез яры буйларындагы, һәм палатка тибындагы лагерьлардагы профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру тәртибе

13.1. Бу бүлек балаларның профильле сменалары һәм төрле тематик юнәлештәге (оборона-спорт, туристлык, экология-биология, иҗади, тарихи-

патриотик, техник, туган якны өйрәнү һәм башкалар) сменалар эшчәнлеген җайга сала.

13.2. Профильле лагерь эшчәнлегенең предметы – профильле лагерь юнәлешенә туры килә торган билгеле бер эшчәнлек өлкәсендә уңышлары булган иҗади сәләтле яки социаль актив балаларны үстерүне тәэмин итү, шулай ук балалар ялына һәм аларны савыктыруга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү. Профильле лагерьда балаларның эшчәнлеге, балаларның белеме, осталыгы һәм күнекмәләре дәрәҗәсеннән, юнәлешле сменаларның тәрбия һәм белем бирү бурычларыннан чыгып, бер яшьтәге балалар берләшмәләрендә (отрядлар, төркемнәр, командалар) дә, төрле яшьтәге балалар берләшмәләрендә дә оештырыла.

13.3. Тематик лагерь эшчәнлегенең предметы – тематик лагерь сменалары программалары юнәлешен (тематикасын) (оборона-спорт, туристлык, экология-биология, иҗади, тарихи-патриотик, техник, туган якны өйрәнү һәм сменалар программаларының (тематикасының) башка юнәлешләрен) исәпкә алып, балаларның мәнфәгатьләрен төрле яклап үстерүне тәэмин итү, шулай ук балалар ялына һәм аларны савыктыруга юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү. Тематик лагерьда балаларның эшчәнлеге, тематик лагерь сменаларының программалары (тематикасы) юнәлешеннән, балалар мәнфәгатьләреннән, тематик лагерьның тәрбия һәм белем бирү бурычларыннан чыгып, бер яшьтәге балалар берләшмәләрендә (отрядлар, төркемнәр, командалар) дә, төрле яшьтәге балалар берләшмәләрендә дә оештырыла.

13.4. Профильле сменаларны һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларны оештыру планы ял оешмасы тарафыннан раслана.

13.5. Шәһәр яны ял лагерьларындагы, шул исәптән Кара диңгез яры буйларындагы һәм палатка тибындагы лагерьлардагы профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда катнашу өчен, балигъ булган яшькә җиткән Катнашучының яки балигъ булган яшькә җитмәгән Катнашучы өчен ата-ананың берсенең (яки законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә, өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы һәм аларны үзләштерүче иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар, спорт әзерлеге узучы балалар, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара килешүләрен тормышка ашыру кысаларында Россия Федерациясе субъектларыннан, якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелә торган балалар һәм яшьләр җибәрелә.

13.6. Шәһәр яны ял лагерьларындагы, шул исәптән Кара диңгез яры буйларындагы һәм палатка тибындагы лагерьлардагы профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда Катнашучының булуы Россия Федерациясе законнары һәм балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) йә балигъ булган яшькә җиткәндә Катнашучының үзе тарафыннан төзелгән шартнамә нигезендә җайга салына. Урнаштыру, урнашуда булышлык күрсәтү, карап тоту һәм эшне оештыру шартлары санитария-эпидемиология кагыйдәләренә һәм гигиена нормативларына, янгын һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлык таләпләренә туры килергә тиеш.

13.7. Ял оешмасы тарафыннан катнашучыларның җыелма исемлеге төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

ата-аналарның (законлы вәкилләрнең (балигъ булмаган гражданнар өчен))

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

Катнашучының туу датасы һәм туган урыны, җенесе;

яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүмат;

14.1 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча ведомствоара комиссия составында:

комиссия составыннан Р.Ш.Моратшинны, Д.И.Фәттаховны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары Тимур Җәүдәт улы Сөләймановны;

«Балалар һәм яшүсмерләр ялын һәм аларны эш белән тәэмин итүне оештыру буенча «Лето» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, Ведомствоара комиссия секретаре Илдар Лукман улы Давлетчинны;

Марат Мансур улы Бариев вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының фәнни-методик советы рәисе»;

Ринат Наил улы Садыйков вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары».

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин